КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 февраль г.Казань № 109

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен күтәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 ел, 28 июнь, 449 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен күтәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен күтәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 ел, 28 июнь, 449 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен күтәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I һәм II куркынычлылык классларындагы куркыныч җитештерү объектларын, һәлакәт булу аркасында зарарлы факторлары урнашу территориясеннән читтә йогынты ясаган зонада яшәгән яки хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырган халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерә торган аеруча радицияле куркыныч һәм атом-төшле куркыныч җитештерүне һәм объектларны, гадәттән тыш югары дәрәҗәдә куркыныч гидротехник корылмаларны һәм югары дәрәҗәдә куркыныч гидротехник корылмаларны эксплуатацияли торган оешмаларның локаль хәбәр итү системалары булдырыла, реконструкцияләнә һәм аларның даими әзер хәлдә булуы тәэмин ителә;»;

7.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I һәм II куркынычлылык классларындагы куркыныч җитештерү объектларын, һәлакәт булу аркасында зарарлы факторлары урнашу территориясеннән читтә йогынты ясаган зонада яшәгән яки хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырган халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерә торган аеруча радицияле куркыныч һәм атом-төшле куркыныч җитештерүне һәм объектларны, гадәттән тыш югары дәрәҗәдә куркыныч гидротехник корылмаларны һәм югары дәрәҗәдә куркыныч гидротехник корылмаларны эксплуатацияли торган оешмаларның локаль хәбәр итү системаларын файдалануга әзерлеген тикшерү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин